ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 февраль 2024 ел №1006

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2595 номерлы, 2023 елның 16 ноябрендәге 11212 номерлы Карарлары редакциясендә), 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3. Башкарма комитетның районнар хакимияте башлыкларына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформадан (алга таба – ЕЦП) файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат җибәрү;

2) ЕЦПдан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат алу.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов